# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Хайваннар дөньясын саклау
һәм аннан нәтиҗәле файдалану
турында

Хайваннар дөньясы - табигать тирәлегенең төп компонентларыннан берсе, биосфераның аерылгысыз состав өлеше, кеше яшәешендә хәлиткеч әһәмияткә ия булган, үзеннән - үзе торгызыла алучы гаять кыйммәтле һәм һәръяклап саклануга һәм нәтиҗәле файдалануга зуруча мохтаҗ табигый байлык ул.

Әлеге Закон Татарстан Республикасының хайваннар дөньясын саклау, аннан фәнни нигезләнгән килеш һәм нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт сәясәтенең принципларын ныгыта, аларның хокукый, икътисадый һәм социаль нигезләрен билгели, хайваннар дөньясын һәм аның яшәү тирәлеген саклауга һәм торгызуга юнәлтелә.

## I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

### 1 статья. Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр

Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

хайваннар дөньясы - Татарстан Республикасы территориясендә һәм акваториясендә даими яисә вакытлыча урнашкан, ярым ирекле шартларда һәм ясалма рәвештә төзелгән тирәлектә тотылучы һәм үрчетелүче табигать иркендәге хайваннарның барлык төрләренең бергәлеге ул;

хайваннар дөньясы объекты - хайваннар дөньясы составын

тәшкил итүче теләсә нинди организм яисә шундый организмнарның бергәлеге (популяция) ул;

яшәү тирәлеге - хайваннар дөньясы объектларының тотрыклы яшәеше һәм аларны ишәйтү өчен кирәкле экологик шартлар тәэмин итүче җир әсте, су һәм һава киңлекләре ул;

хайваннар дөньясыннан файдалану - хайваннар дөньясы объектларын яшәү тирәлегеннән аерып алу яисә аннан башка гына хуҗалык, фәнни, мәдәни, зәүкый һәм башка максатларда файдалану ул;

аучылык - табигать иркендәге хайваннар дөньясы объектларын кулга төшерү максатларында махсус алымнар һәм кораллар ярдәмендә хайваннар дөньясыннан файдалану төре ул;

балыкчылык - махсус алымнар һәм кораллар ярдәмендә балыкларны, умырткасыз су хайваннарын аулау максатларында хайваннар дөньясыннан файдалану ул;

хайваннар дөньясыннан файдаланучылар - үзләренә Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары тарафыннан хайваннар дөньясыннан файдалану хокукы тапшырылган гражданнар һәм юридик затлар ул;

лицензия - хайваннар дөньясы объектларыннан үзендә күрсәтелгән хуҗалык эшчәнлеген һәм хайваннар дөньясы объектларыннан файдалануга бәйле башка эшчәнлекне башкару хокукын бирүче махсус рөхсәт ул;

озак вакытлы лицензия - хайваннар дөньясы объектларын файдалану һәм саклау белән бәйле хуҗалык эшчәнлеген һәм башка эшчәнлекне башкару өчен озак вакытка бирелүче махсус рөхсәт ул;

бер мәртәбә бирелүче исемле лицензия - хайваннар дөньясының билгеле бер объектларыннан бер мәртәбә файдалану өчен бирелүче махсус рөхсәт ул, анда рөхсәтнең гамәлдә булу урыны һәм вакыты, шулай ук файдалану рөхсәт ителгән хайваннар дөньясы объектларының микъдары күрсәтелә.

## 2 статья. Хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турындагы законнар

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар дөньясын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге мөнәсәбәтләр

әлеге Закон һәм башка закон актлары белән җайга салына.

3 статья. Хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында Татарстан Республикасы законнарының бурычлары

Хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында Татарстан Республикасы законнарының бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

табигать иркендә йөрүче кыргый хайваннарның тереклеге өчен уңай шартларны саклау, аларның биологик күптөрлелеген саклау, бу өлкәдә законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгыту максатларында хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салу;

гражданнарның һәм юридик затларның - хайваннар дөньясы объектларыннан файдаланучыларның хокукларын регламентлаштыру;

хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге хокук бозулар өчен җаваплылык дәрәҗәсен билгеләү.

4 статья. Хайваннар дөньясына карата милекчелек

Татарстан Республикасы территориясендә табигать иркендә йөрүче хайваннар дөньясы объектлары аның дәүләт милке була.

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар дөньясы объектларына милекчелек хокукын чикләү, аларны биләү, алардан файдалану, аларга хуҗа булу законнар һәм хөкүмәтара килешүләр белән билгеләнә.

Билгеләнгән тәртиптә яшәү тирәлегеннән аерып алынган хайваннар дөньясы объектлары хосусый һәм дәүләт (шул исәптән республика һәм коммуналь) милкендә, җирле үзидарә милкендә һәм җәмәгать берләшмәләре милкендә булырга мөмкин.

## 2 бүлек. Хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсе

5 статья. Хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсе

Хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсе хайваннар дөньясын дәүләт тарафыннан исәпкә алудан һәм аның дәүләт кадастрын алып барудан, хайваннар дөньясы объектларын саклауны, торгызуны һәм файдалануны дәүләт тарафыннан тикшереп торудан, хайваннар дөньясы объектларыннан файдалануны дәүләт тарафыннан җайга салудан һәм хайваннар дөньясы объектларының дәүләт мониторингын алып барудан гыйбарәт.

Хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы, хайваннар дөньясын саклау, аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле башка дәүләт органнары башкара.

Хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау, тикшереп тору һәм алардан файдалануны җайга салу буенча махсус вәкаләтле дәүләт органнарының һәрберсенең вәкаләтләре Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслаучы нигезләмә тарафыннан билгеләнә.

6 статья. Хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалануның төп принциплары

Хайваннар дөньясына йогынты ясаучы хуҗалык, идарә һәм башка төрле эшчәнлек башкаргандагы төп принциплар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

хайваннар дөньясының тотрыклы тереклеген тәэмин итүгә һәм яшәү тирәлеген саклауга юнәлдерелгән эшчәнлекнең өстенлекле булуы;

хайваннар дөньясы байлыкларыннан нәтиҗәле һәм фәнни нигезләнгән килеш файдалану, аны торгызуның һәм биологик күптөрлелеген саклауның зарурлыгы, яшәү тирәлегенә зыян салуларны булдырмый калу;

хайваннар дөньясыннан түләүле махсус файдалану һәм түләүсез гомуми файдалану;

хайваннар дөньясы объектларыннан файдалану хокукы буенча гражданнарның бертигез булуы һәм социаль гаделлек булу;

хайваннар дөньясын саклау һәм аннын нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге дәүләт контроле вазыйфаларының һәм хайваннар дөньясы объектларыннан хуҗалык максатларында файдалану вазыйфаларының бер үк зат тарафыннан башкарылуына юл куймау;

хайваннар дөньясы турындагы законнарның таләпләрен һичшиксез үтәү, аларны бозган өчен җаваплылыкның котылгысыз булуы;

хайваннар дөньясыннан нәтиҗәле файдалану һәм аны саклау бурычларын хәл итүгә гражданнарны һәм иҗтимагый берләшмәләрне җәлеп итү;

хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә халыкара хокукның өстенлеге.

<u>7 статья.</u> Хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнарының вәкаләтләре

Хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары карамагына түбәндәгеләр керә:

хайваннар дөньясының кайбер төрләреннән файдалануны җайга салу;

хайваннар дөньясының кайбер төрләрен саклауны һәм алардан нәтиҗәле файдалануны дәүләт тарафыннан тикшереп тору;

хайваннар дөньясының аерым төрләреннән файдалану өчен лицензияләр бирү;

хайваннар дөньясының кайбер төрләреннән файдалануның кагыйдәләрен, лимитларын һәм аларны табигатьтән аерып алуның квоталарын әзерләү;

хайваннар дөньясының аерым төрләрен дәүләт тарафыннан гомуми исәпкә алу һәм аларның халәтен бәяләү;

хайваннар дөньясының аерым төрләре халәте турындагы мәгълүматларны җыю, саклау, эшкәртү, анализлау һәм тарату.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә Татарс-

тан Республикасының махсус вәкаләтле органнары карамагына хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану буенча мөнәсәбәтләрне җайга салучы башка мәсьәләләрне дә кертергә мөмкин.

8 статья. Хайваннар дөньясы объектларын дәүләт тарафыннан исәпкә алу һәм аларның дәүләт кадастры

Хайваннар дөньясын саклауны тәэмин итү һәм аның байлыкларын нәтиҗәле файдалануны оештыру йөзеннән, хайваннар дөньясы объектлары һәм алардан файдалану дәүләт тарафыннан исәпкә алына, хайваннар дөньясы объектларының дәүләт кадастры алып барыла.

Хайваннар дөньясы объектларының дәүләт кадастрына түбәндәгеләр керә: хайваннар дөньясы объектларының географик таралышы һәм аларның саны турындагы белешмәләрнең бирелеге; яшәү тирәлекләренең сыйфатламасы; хайваннар дөньясы байлыкларының хуҗалык итүдә кулланылышы хакындагы мәгълүматлар; зоопаркларда, зообакчаларда, питомникларда тотылучы хайваннар турындагы белешмәләр һәм башка кирәкле мәгълүматлар.

Хайваннар дөньясының халәтен дәүләт тарафыннан исәпкә алуны һәм аның хакында фаразлауны хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары гамәлгә ашыра.

Хайваннар дөньясыннан файдаланучылар үзләре кулланган хайваннар дөньясы объектларын һәм аларны табигатьтән аерып алу күләмнәрен ел саен исәпкә алырга һәм алынган мәгълүматларны хайваннар дөньясы объектларын һәм яшәү тирәлеген саклау һәм алардан файдалануны тикшереп тору һәм җайга салу буенча махсус вәкаләтле дәүләт органына тапшырырга тиеш.

Хайваннар дөньясы объектларын дәүләт тарафыннан исәпкә алу һәм аларның дәүләт кадастрын алып бару Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

9 статья. Хайваннар дөньясы объектларының дәүләт мониторингы

Хайваннар дөньясы объектларының дәүләт мониторингы - хайваннар дөньясы объектларындагы һәм аларның яшәү тирәлегендәге үзгәрешләрне вакытында билгеләү, аларга бәяләмә бирү, фаразлау, тискәре күренешләрне булдырмый калу, була калса, вакытында туктату өчен хайваннар дөньясы объектларының халәтен, аларның санын һәм таралышын, шулай ук яшәү тирәлекләренең корылышын һәм сыйфатын даими рәвештә күзәтеп тору системасы ул.

Хайваннар дөньясы объектларының дәүләт мониторингын алып бару тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

3 бүлек. Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм ишәйтү

10 статья. Хайваннар дөньясы объектларын саклауны һәм ишәйтүне оештыру

Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм ишәйтү түбәндәге юллар белән тәэмин ителә:

хайваннар дөньясы объектларын саклау, торгызу һәм алардан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә нормалар һәм кагыйдәләр билгеләү;

хайваннар дөньясыннан файдалануга тыюлар һәм чикләүләр билгеләү;

хайваннар дөньясыннан рөхсәтсез файдалануны һәм хайваннар дөньясыннан файдалануның билгеләнгән тәртибен башкача бозуларны булдырмый калу;

Хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеген, миграция юлларын, үрчү, кышлау һәм даими рәвештә тупланып тору урыннарының халәтен уңайлы итеп тоту;

җитештерү гамәлләрен башкарганда хайваннар дөньясы объектларының һәлак булуларын булдырмый калу;

махсус сакланылучы табигать территорияләрен оештыру;

хайваннар дөньясының сирәк очрый торган һәм бетү куркынычы булган объектларын яклау;

хайваннар дөньясы объектларын үрчетү, аларның генетик

фондын саклап калу һәм аларны табигый яшәү тирәлегендә торгызу буенча махсуслаштырылган үзәкләр (зоопарклар, питомниклар, балык питомниклары һәм башкалар) төзү;

эпидемияләр, авырулар килеп чыгу очракларында, табигый бәла-казалар һәм башка сәбәпләр аркасында һәлак булу янаганда хайваннар дөньясы объектларына ярдәм күрсәтү;

хайваннар дөньясы объектларын саклау, ишәйтү һәм алардан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә фәнни тикшеренүләр оештыру;

хуҗалык итү проектларына экологик экспертиза ясау, гамәлдәге предприятиеләрнең хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлегенә йогынтысын тикшереп тору;

хайваннар дөньясы объектларын саклауны пропагандалау һәм гражданнарга экологик тәрбия бирү;

хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау буенча башка гамәлләр башкару.

Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм ишәйтү буенча башкарылучы гамәлләр табигатьтән файдалануның башка төрләренә зыян китерергә тиеш түгел.

<u>11 статья.</u> Дәүләтнең экологик экспертизасы

Түбәндәгеләр дәүләтнең мәҗбүри экологик экспертизасын узарга тиешләр: промышленность, транспорт, элемтә һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләрен, корылмаларын һәм башка төр объектларны урнаштыру һәм төзү проектлары, техник-икътисадый нигезләүләре, шулай ук технологик процесслар, яңа техника, химик матдәләр һәм препаратлар, норматив-техник документлар, аучылык, балыкчылык һәм файдаланыла торган башка урыннарны бирү һәм кире алу белән бәйле проектлар.

Хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләтнең экологик экспертизасы законнар нигезендә Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы тарафыннан хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә башка махсус вәкаләтле дәүләт органнары катнашында гамәлгә ашырыла.

12 статья. Хайваннар дөньясы объектларыннан файдалану буенча чикләүләр һәм тыюлар билгеләү

Хайваннар дөньясының аерым объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау һәм ишәйтү йөзеннән, хайваннар дөньясының аерым төрләрен куллану Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан хайваннар дөньясы объектларыннан файдалану төре үзгәртелергә, чикләнергә, туктатып торылырга яисә бөтенләй тыелырга мөмкин.

Хайваннар дөньясы объектларын саклап калуга, хайваннар дөньясы объектларын яшәү тирәлегеннән аерып алуны тыйган килеш, бу объектларны табигатьтән аерып алмыйча гына мәдәни-агарту, ял итү һәм аәукый максатларда файдалануны оештыру юлы белән ирешелергә мөмкин, моңа экологик туризмны оештыру да керә.

13 статья. Хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеген саклап калу

Хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеген үзгәртерлек һәм аларның үрчүе, аларны симертү, аларның ял итүе шартларын һәм миграция юлларын кыенлаштырырлык теләсә нинди эшчәнлек хайваннар дөньясын саклауны тәэмин итүче таләпләрне үтәгән килеш кенә башкарылырга тиеш.

Торак пунктларын, предприятиеләрне, корылмаларны һәм башка объектларны урнаштырганда, проектлаштырганда һәм төзегәндә, гамәлдәге технологик процессларны камилләштергәндә һәм яңаларын гамәлгә керткәндә, сазлык җирләрне, яр буйларын һәм куаклыклар булган территорияләрне хуҗалык әйләнешенә керткәндә, җирләрне мелиорацияләгәндә, урманнардан файдаланганда, геологик эзләнү эшләрен уздырганда, файдалы казылмалар чыгарганда, авыл хуҗалыгы хайваннары өчен көтүлек һәм җәйләү урыннарын билгеләгәндә, сәяхәт юлларын эзерләгәндә һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын оештырганда һәм хуҗалык эшчәнлегенең башка төрләрен башкарганда хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеген саклап калу буенча һәм аларның үрчүе, аларны симертү, аларның ял итү шартларын һәм миграция юлларын саклап калу бу-

енча, шулай ук яшәү тирәлеге сыйфатындагы аеруча әһәмияткә ия булган кишәрлекләрнең кагылгысызлыгын тәэмин итү буенча гамәлләр күз алдында тотылырга һәм уздырылырга тиеш.

Аэродромнарны, тимер юл, шоссе, торба үткәргеч һәм башка төр транспорт магистральләрен, электрүткәргеч һәм элемтә линияләрен, шулай ук каналлар, буалар һәм бүтән гидротехник корылмаларны урнаштырганда, проектлаштырганда, төзегәндә һәм үзгәртеп корганда төзегәндә хайваннарның миграция юлларын һәм даими тупланып тору урыннарын, шул исәптән үрчү һәм кышлау чорында да, саклап калуны тәэмин итәрлек гамәлләр эзерләнергә һәм тормышка ашырылырга тиеш.

Хайваннар дөньясының сирәк очрый торган, юкка чыгу куркынычы булган һәм хуҗалык итү, фәнни яктан кыйммәтле объектларының тереклек итү урыннарын саклау йөзеннән, җирле әһәмияткә ия булган территорияләрнең һәм акваторияләрнең саклаучан кишәрлекләре бүленеп алына, әмма бу кишәрлекләрдә аларның тереклеге өчен (үрчүләре, яшь хайваннарны үстерү, симертү, ял итү, миграция һәм башкалар өчен) тиешле шартлар булырга тиеш. Территорияләрнең һәм акваторияләрнең сакланылучы кишәрлекләрендә хуҗалык эшчәнлегенең хайваннар дөньясы объектларының яшәеш циклын бозарлык кайбер төрләре тыела яисә, әгәр алар хайваннар дөньясы объектларының тереклек циклларын бозсалар, аларны уздыру чоры һәм технологияләре регламентлана.

Сакланылучы кишәрлекләр, дәүләт табигать тыюлыгы статусы бирелеп, Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары нигезендә оештырылалар. Хуҗалык эшчәнлеген чикләгән килеш сакланылучы кишәрлекләр бүлеп бирелгәндә сакланылучы кишәрлекләрнең милекчесенә, биләүчесенә яисә арендачысына законнар нигезендә компенсация түләнә.

<u>14 статья.</u> Дәүләт табигать тыюлыкларында һәм башка шундый махсус сакланылучы табигать территорияләрендә һәм акваторияләрендә хайваннар дөньясы объектларын саклау

Дәүләт табигать тыюлыклары территорияләрендә һәм милли

паркларның тыюлык зоналарында хайваннар дөньясыннан файдалануның тиешле максатларга туры килмәүче барлык төрләре, шулай ук кыргый хайваннарның яшәү тирәлеген үзгәртүгә китерерлек һәр эшчәнлек тыела.

Дәүләт табигать тыюлыкларының сакланылучы зоналары, милли паркларның башка зоналары һәм бүтән төр махсус сакланылучы табигать территорияләре чикләрендә хайваннар дөньясыннан файдаланының һәр төре, шулай ук хайваннар дөньясын саклау максатларына каршы килерлек һәр эшчәнлек хайваннар дөньясын саклау, аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан регламентлана.

Дәүләтнең табигать тыюлыклары территорияләрендә мәдәни-агарту, тәрбияви, ял итү һәм зәүкый максатларда хайваннар дөньясы объектларыннан файдалану бары тик аларның сакланылучы зоналары чикләрендә генә, ә милли паркларда - музей экспозицияләре, күзәтү мәйданчыклары, вольерлар,табигать һәм хайваннар дөньясы белән танышуны тәэмин итәрлек башка төр корылмалар белән җиһазландырылган махсус билгеләнгән кишәрлекләрдә генә рөхсәт ителә.

Дәүләт табигать тыюлыклары, милли парклар, табигать ядкярләре территорияләрендә һәм акваторияләрендә һәм махсус сакланылучы табигать территорияләрендә хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау законнар һәм башка норматив-хокукый актлар нигезендә оештырыла һәм гамәлгә ашырыла.

Махсус сакланылучы табигать территорияләрендә җайга салу гамәлләре бары Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы белән килешенеп кенә башкарыла.

<u>15 статья.</u> Хайваннар дөньясының сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы булган объектларын саклау

Хайваннар дөньясының сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы булган объектлары Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелә.

Кызыл китапка кертелгән хайваннар дөньясы объектларын һә-

лакәткә, аларның санын киметүгә яисә яшәү тирәлеген бозуга китерерлек гамәлләр кылу рөхсәт ителми. Кызыл китапка кертелгән хайваннар яши торган җир-суларда хуҗалык эшчәнлеген алып баручы субъектлар әлеге хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм аларны ишәйтү өчен законнар нигезендә җаваплы булалар.

Юкка чыгу куркынычы булган хайван төрләрен саклау өчен аларны үрчетү буенча тиешле шартлар булдыру гамәлләре башкарылырга тиеш, махсус питомниклар оештыру да шуңа керә.

Кызыл китапка кертелгән хайваннарны аулау, аларны, шулай ук алардан алынган продуктларны сатып алу, сатып җибәрү, аларны Татарстан Республикасыннан читкә чыгару, бу хайваннарны тоткында тоту һәм аларны табигать иркенә чыгару махсус очракларда гына, бары тик Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы рөхсәте буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан каралган тәртиптә генә башкарыла.

**16 статья.** Хайваннар дөньясы объектларын күчерү, яңа климатка җайлаштыру һәм гибридлаштыру

Хайваннарны яшәү өчен яңа урыннарга күчерү, хайваннар дөньясы объектларын яңа климатка җайлаштыру, шулай ук хайваннар дөньясы объектларын гибридлаштыру гамәлләрен кылу, вәкаләтле фәнни оешмаларның уңай бәяләмәсе булганда һәм экологик хәвефсезлек таләпләрен исәпкә алып, бары тик Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы рөхсәте белән генә башкарыла. Хайваннар дөньясы объектларын рөхсәтсез күчерү, яңа климатка җайлаштыру һәм гибридлаштыру тыела.

**17 статья.** Җитештерү эшләрен башкарганда, транспорт чараларын, элемтә һәм электр линияләреннән файдаланганда хайваннар дөньясы объектларының авыруларын һәм һәлак булуларын булдырмый калу

Юридик затлар һәм гражданнар авыл хуҗалыгы эшләрен һәм башка эшләрне башкарганда, шулай ук ирригацион һәм мелиоратив системалардан, транспорт чараларыннан, элемтә һәм электр лини-

яләреннән файдаланганда хайваннар дөньясы объектларының авыруларын һәм һәлак булуларын булдырмый калу буенча чаралар күрергә тиеш.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш ветеринария идарәсе һәм Татарстан Республикасы Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты хайваннар дөньясы объектларының авыруларын һәм авыруларның таралуын, хайваннар дөньясы объектларының авырулары ачылган барлык очракларны теркәүне тикшереп торалар һәм авырулар килеп чыгуны, аларның таралуын булдырмый һәм аларны бетерү буенча тиешле чаралар күрәләр. Хайваннар дөньясы объектларының кешеләр сәламәтлеге һәм йорт хайваннары өчен куркыныч авырулары килеп чыккан очракта Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш ветеринария идарәсе һәм Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты, шулай ук хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары бу хакта Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарына хәбәр итәргә, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары аша халыкка җиткерергә тиешләр.

Хайваннар дөньясы объектларының авыруларын һәм һәлак булуларын булдырмауны, шулай ук хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеген начарайтмауны гарантияләүче чараларны башкармый торып, хайваннар дөньясы объектлары һәм аларның яшәү тирәлеге өчен куркыныч булган корыган үсемлекләрне яндыру, агулы химикатларны, ашламаларны һәм башка материалларны, җитештерү чималларын һәм калдыкларын саклау һәм куллану рөхсәт ителми.

Үсемлекләрне саклаучы химик препаратларны һәм башка препаратларны хайваннар дөньясына аларның зарарлы йогынтысын киметү максатларында куллану агротехник, селекция-генетик, биологик һәм башка гамәлләр белән бер үк вакытта башкарылырга тиеш.

Химик һәм биологик препаратларны әзерләү, сынау кагыйдәләре һәм аларны куллану нормативлары, шулай ук әлеге препаратларның исемлеге, халыкара стандартларны исәпкә алып, Татарстан Республикасының Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты һәм Татарстан Респуб-

243



ликасының агрохимия хезмәте тарафыннан расланa.

18 статья. Хайваннар дөньясы объектларының санын җайга салу

Халыкның сәламәтлеген саклау, кешеләр тормышына куркыныч янауны бетерү, авыл хуҗалыгы һәм башка йорт хайваннарын авырулардан саклау, хайваннар дөньясына һәм аларның яшәү тирәлегенә зыян салуны булдырмый калу өчен хайваннар дөньясындагы аерым объектларның санын җайга салу гамәлләре башкарыла.

Хайваннар дөньясындагы аерым объектларның санын җайга салу хайваннар дөньясының башка объектларына зыян китерми торган һәм аларның яшәү тирәлеген саклауны тәэмин итүче ысуллар белән, бу өлкәдәге проблемаларны хәл итүче фәнни оешмаларның бәяләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы белән килешеп башкарыла.

19 статья. Хайваннар дөньясы объектларын ирекләрен чикләү шартларында һәм ясалма яшәү тирәлегендә тоту һәм үрчетү

Хайваннар дөньясы объектларын ирекләрен чикләү шартларында һәм ясалма яшәү тирәлегендә тоту һәм үрчетү бары тик Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы ризалыгы белән генә рөхсәт ителә.

Хайваннар дөньясы объектларына хуҗа булган яисә аларны тоту һәм үрчетү белән шөгыльләнүче юридик затлар һәм гражданнар алар белән шәфкатьле эш итәргә, аларны тотуга карата билгеләнгән санитария-ветеринария һәм зоогигиена кагыйдәләрен үтәргә тиешләр. Күрсәтелгән таләпләрне үтәмәгән өчен законнар нигезендә юридик җаваплы булалар, ә хайваннар дөньясы объектлары суд тәртибендә конфискацияләнергә тиеш.

20 статья. Зоологик коллекцияләр

Милек рәвешләренә карамастан, фәнни, мәдәни-агарту, укыту-тәрбияләү һәм эстетик кыйммәткә ия булган зоологик коллекци-

244



ялэр (зоология институтларының, университетларның, музейларның фондларындагы фәнни коллекцияләр, шулай ук хайван карачкыларының, хайваннар дөньясы объектлары препаратларының һәм өлешләренең җыелмасы, зоопаркларның, зообакчаларның, питомникларның, аквариумнарның һәм башка учреждениеләрнең тере коллекцияләре) дәүләт тарафыннан исәпкә алынырга тиеш.

Зоологик коллекцияләрне яисә аерым экспонатларны дәүләт тарафыннан исәпкә алу, тулыландыру, саклау, сатып алу, сату, күчерү, Татарстан Республикасыннан читкә чыгару һәм анда кертү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Шундый коллекцияләргә хуҗа булган юридик затлар һәм гражданнар аларны исәпкә алуның, саклауның, куллануның һәм тулыландыруның билгеләнгән тәртибен үтәргә тиешләр.

4 бүлек. Хайваннар дөньясыннан файдалану

21 статья. Хайваннар дөньясыннан файдалану төрләре

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар дөньясыннан файдалануның түбәндәге төрләре гамәлгә ашырылырга мөмкин:

аучылык;

балыкчылык, судагы умырткасызларны тоту да шунда керә;

аучылык һәм балыкчылык объектларына кермәгән хайваннар дөньясы объектларын тоту;

хайваннар дөньясыннан фәнни, мәдәни-агарту, тәрбияләү, ял итү максатларында, зәүкый һәм башка максатларда файдалану;

хайваннар дөньясы объектларының - туфрак ясаучыларның, әйләнә-тирәдәге табигый санитарларның, үсемлекләрне серкәләндерүчеләрнең, биофильтрларның һәм башкаларның тереклек эшчәнлегендәге файдалы үзенчәлекләрен куллану;

хайваннар дөньясы объектларын тереклек эшчәнлеге продуктларын алу максатларында файдалану.

Татарстан Республикасы законнарында хайваннар дөньясыннан башкача файдалану да каралырга мөмкин.

22 статья. Хайваннар дөньясыннан файдалану шартлары

Табигый тирәлектән лицензиясез генә аерып алулары тыелган хайваннар дөньясы объектларының исемлеген Татарстан Республикасының хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге махсус вәкаләтле органнары билгели.

Хайваннар дөньясы объектларыннан махсус файдалану юридик затларга - лицензия нигезендә, гражданнарга бер мәртәбә бирелүче исемле лицензияләр нигезендә түләү бәрабәренә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнүче тәртиптә һәм күләмнәрдә рөхсәт ителә.

Хайваннар дөньясыннан гомуми файдалану аларны табигый яшәү тирәлегеннән аерып алып һәм аерып алмыйча гына файдалану түләүсез була.

Хайваннар дөньясыннан файдалану әлеге Закон, башка норматив-хокукый актлар нигезендә әзерләнүче стандартларны, кагыйдәләрне, лимитларны һәм нормативларны бозмыйча гына гамәлгә ашырыла.

Хайваннар дөньясыннан файдалану хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм торгызу, аларның яшәү тирәлеген саклау буенча гамәлләр системасы белән бергә башкарыла.

Бер үк территориядә яисә акваториядә хайваннар дөньясының берничә төреннән файдаланырга мөмкин, әмма бер төрдән файдалану икенче төрдән файдалануга комачаулык итмәскә тиеш.

22 статья. Хайваннар дөньясыннан файдаланучыларның хокуклары һәм бурычлары

Хайваннар дөньясыннан файдаланучылар түбәндәге хокукларга ия:

кулга төшерелгән хайваннар дөньясы объектларына һәм алардан алынган продукциягә карата милекчелеккә;

ярдәмче хуҗалык тотарга, хайваннар дөньясыннан файдалануның рөхсәт ителгән төрләрен гамәлгә ашыру барышында алынган продукцияне эшкәртү дә шуңа керә, хайваннар дөньясы объектларыннан әйберләр җитештерүгә;

юридик затлар һәм гражданнар тарафыннан хокукка каршы гамәлләр кылу аркасында хайваннар дөньясы объектларын һәлак

итәрлек, хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеген начарайтырлык китерелгән зыян өчен, хайваннар дөньясыннан файдалану хокукын, алынган продукциягә милекчелек хокукын нигезсез чикләгән өчен, шулай ук җирләрнең статусы үзгәрү барышында хайваннар дөньясыннан файдалану хокукын туктаткан очракларда, алынмаган табышны да кертеп, законнарда билгеләнгән тәртиптә дәгъва белдерергә.

Хайваннар дөньясыннан файдаланучылар түбәндәгеләрне үтәргә бурычлы:

хайваннар дөньясының бары тик лицензиядә күрсәтелгән төрләреннән генә файдаланырга;

хайваннар дөньясы объектлаынннан файдалануның билгеләнгән кагыйдәләрен, нормаларын һәм вакытларын үтәргә;

хайваннар дөньясыннан файдаланганда табигый бергәлек бөтенлеген бозмаучы ысулларны кулланырга;

хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеген бозуга яисә начарайтуга юл куймаска;

файдаланылучы хайваннар дөньясы объектларының торышын исәпкә алуны һәм бәяләүне, шулай ук аларның яшәү тирәлегенең торышын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

хайваннар дөньясын торгызуга юнәлдерелгән тиешле комплекслы гамәлләрне үздырырга;

хайваннар дөньясын саклаганда дәүләт органнарына һәръяклы ярдәм күрсәтергә;

сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы булган хайваннар дөньясы объектларын саклауны һәм торгызуны тәэмин итәргә;

хайваннар дөньясыннан файдаланганда кешелекле алымнар кулланырга.

Татарстан Республикасы территориясендә, законнарда һәм башка норматив актларда каралганнан тыш, хайван аягын әләктерүче капкыннар һәм әлмәк тозаклар куллану тыела.

Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда хайваннар дөньясыннан файдаланучыларның хокуклары арттырылырга яисә чикләнергә мөмкин.

24 статья. Аучылык

Аучылык һәм аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге мөнәсәбәтләр тиешле законнар һәм башка норматив-хокукый актлар белән җайга

салына.

Хайваннар дөньясы объектларының аучылык объектларына кертелгән исемлеге, объектларның статусыннан, санынннан, файдалану традицияләреннән, алынучы продукцияләрнең төрләреннән һәм сыйфатыннан чыгып, Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы белән килешеп, хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану буенча Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан төзелә һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

25 статья. Балыкчылык

Балыкчылык өлкәсендәге мөнәсәбәтләр тиешле законнар һәм башка норматив-хокукый актлар белән җайга салына.

26 статья. Аучылык һәм балыкчылык объектларына кертелмәгән хайваннар дөньясы объектларын кулга төшерү

Аучылык һәм балыкчылык объектларына кертелмәгән хайваннар дөньясы объектларын кулга төшерү бары тик Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы рөхсәте белән генә мөмкин.

Аучылык һәм балыкчылык объектларына кертелмәгән хайваннар дөньясы объектларын кулга төшерү тәртибе тиешле законнар һәм башка норматив-хокукый актлар белән билгеләнә.

27 статья. Хайваннар дөньясыннан фәнни, мәдәни-агарту, тәрбияләү, ял итү максатларында һәм зәвыклый максатларда файдалану

Хайваннар дөньясыннан фәнни, мәдәни-агарту, тәрбияләү, ял итү максатларында һәм зәвыклый максатларда хайваннар дөньясы объектларын яшәү тирәлегеннән аерып алмыйча гына төрлечә күзәтеп, уылдык чәчтереп, фотога төшереп һәм тикшеренүнең башка ысулларын кулланып файдалану махсус рөхсәттән башка һәм түләүсез мөмкин, әмма бу ысуллар, мондый рәвешләрдән файдалану ты-

елмаган очраклардан гайре, хайваннар дөньясына яисә аларның яшәү тирәлегенә зыян китермәскә һәм хайваннар дөньясыннан файдаланучыларның хокукларын, шулай ук җир хуҗаларының (җирдән файдаланучыларның), урман фонды хуҗаларының хокукларын бозмаска тиеш.

Хайваннар дөньясыннан фәнни, мәдәни-агарту, тәрбияләү, ял итү һәм зәүкый максатларда хайваннар дөньясы объектларын табигый тирәлектән аерып алып файдалану бары тик билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы бирә торган рөхсәт буенча гына мөмкин.

28 статья. Хайваннар дөньясы объектларының тереклек эшчәнлегендәге файдалы үзенчәлекләрне куллану

Хайваннар дөньясы объектларының (туфрак ясаучыларның, тирәлектәге табигый санитарларның, үсемлекләрне серкәләндерүчеләрнең һәм башкаларның) тереклек эшчәнлегендәге файдалы үзенчәлекләрне, әлеге Законда һәм башка закон актларында билгеләнгән очраклардан гайре, яшәү тирәлегеннән аерып алмыйча куллану рөхсәт ителә.

29 статья. Хайваннар дөньясы объектларыннан аларның тереклек эшчәнлеге продуктларын алу максатларында файдалану

Хайваннар дөньясы объектларын яшәү тирәлегеннән аерып алмыйча һәм аларны һәлак итмичә, шулай ук аларның яшәү тирәлеген бозмыйча хайваннар дөньясы объектларыннан аларның тереклек эшчәнлеге продуктларын (кыргый бал кортлары балын, балавызын һ.б.) алу максатларында файдалану рөхсәт ителә.

Хайваннар дөньясы объектларыннан аларның тереклек эшчәнлеге продуктларын алу максатларында файдалану кагыйдәләре хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан билгеләнә.

30 статья. Хайваннар дөньясыннан файдалану хокукын туктату нигезләре һәм тәртибе

Хайваннар дөньясыннан файдалану тулысынча яисә өлешчә түбәндәге очракларда туктатыла:

файдаланудан баш тартканда;

файдалануның билгеләнгән вакыты узгач;

әйләнә-тирә табигать мохитен саклау турындагы законнарны һәм хайваннар дөньясыннан файдалану лицензиясендә күрсәтелгән шартларны бозганда;

хайваннар дөньясы объектларын саклау максатларында алардан файдалануны туктату зарурлыгы килеп чыкканда;

файдалану хокукы бирелгән предприятие, учреждение, оешма бетерелгәндә;

территорияне, акваторияне хайваннар дөньясыннан файдалануны күздә тотмаган дәүләт мәнфәгатьләре өчен кулланганда.

Әлеге статьяның 1 өлешендәге 2,3,4 һәм 6 абзацларында каралган очракларда хайваннар дөньясыннан файдалану хокукы хайваннар дөньясыннан файдалану өчен тиешле органнар тарафыннан бирелгән лицензияләрен юкка чыгару юлы белән туктатыла.

Әлеге статьяның 1 өлешендәге 5 һәм 7 абзацларында каралган очракларда хайваннар дөньясыннан файдалану хокукы, яклар белән килешеп, лицензияне юкка чыгару юлы белән яисә суд тәртибендә туктатыла.

5 бүлек. Хайваннар дөньясы объектларын саклауны һәм аннан нәтиҗәле файдалануны икътисадый җайга салу

31 статья. Хайваннар дөньясы объектларын саклауны һәм аннан нәтиҗәле файдалануны икътисадый җайга салуның максатлары һәм бурычлары

Хайваннар дөньясы объектларын саклауны һәм аннан нәтиҗәле файдалануны икътисадый җайга салу түбәндәгеләрне күздә тота:

хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә табигатьтән файдаланучылар арасындагы икътисадый мөнәсәбәтләр урнаштыруны һәм аларны җайга салуны;

хайваннар дөньясыннан файдаланган өчен түләүләр системасын оештыруны һәм хайваннар дөньясы объектларын саклауның, торгызуның һәм алардан нәтиҗәле файдалануның тотрыклы икътисадый нигезләрен булдыруны;

хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт мәнфәгатьләрен икътисадый яклауны;

хайваннар дөньясыннан файдаланучыларны икътисадый яклауны.

32 статья. Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалануны икътисадый җайга салу төзелмәсе

Хайваннар дөньясын саклауны һәм аннан нәтиҗәле файдалануны икътисадый җайга салуга түбәндәгеләр керә:

хайваннар дөньясы объектларын исәпкә алу һәм икътисадый бәяләү;

хайваннар дөньясыннан файдаланган өчен түләүләрнең икътисадый нигезләнгән системасы;

хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм торгызу буенча гамәлләрне бюджеттан финанслау;

хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турындагы законнарны бозган өчен штрафларның һәм дәгъваларның икътисадый нигезләнгән системасы;

хайваннар дөньясы объектларын законсыз кулга төшерү өчен кулланылган һәм конфискацияләнгән коралларны, шул исәптән транспорт чараларын һәм продукцияне сатудан алынган акчаларны, шулай ук юридик һәм физик затларның ирекле кертемнәрен законнарда каралган тәртиптә максатчыл файдалану.

33 статья. Хайваннар дөньясыннан файдаланган өчен түләүләр

Хайваннар дөньясыннан файдаланган өчен түләүләргә хайваннар дөньясыннан файдаланган өчен түләү керә.

Хайваннар дөньясыннан файдаланган өчен түләү кертү табигатьтән файдаланучыларны хайваннар дөньясы объектларын, аларның яшәү тирәлеген саклау буенча гамәлләрне үтәүдән һәм үзләре

тарафыннан китерелгән зыянны түләүдән азат итми.

Хайваннар дөньясыннан файдаланган өчен түләү Татарстан Республикасының Республика бюджетына кертелә.

Татарстан Республикасының Республика бюджетына кертелүче акчалар хайваннар дөньясы объектларыннан комплекслы файдалану, аларны саклау һәм торгызу, тискәре йогынтылардан саклау, хайваннар деньясы объектларының дәүләт мониторингын кертү буенча тиешле гамәлләрне тормышка ашыру өчен, фәнни-тикшеренү эшләре, шулай ук хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау, торгызу һәм алардан тотрыклы файдалану белән бәйле башка максатлар өчен кулланыла.

34 статья. Хайваннар деньясы объектларын саклауны, торгызауны һәм алардан нәтиҗәле файдалануны икътисадый кызыксындыру

Хайваннар дөньясы объектларын саклауны, торгызауны һәм алардан нәтиҗәле файдалануны икътисадый кызыксындыруга түбәндәгеләр керә:

хайваннар дөньясы объектларын саклауны, торгызуны һәм алардан тотрыклы файдалануны, шулай ук аларның яшәү тирәлеген саклауны һәм аның торышын яхшыртуны тәэмин итүче юридик затларга һәм гражданнарга бирелүче салымнарны һәм башка ташламаларны билгеләү;

хайваннар дөньясын нәтиҗәле саклау һәм торгызау буенча эшләр башкару өчен юридик затларга ташламалы кредитлар бирү;

хайваннар дөньясын саклауны гамәлгә ашыручы урындагы затларны һәм гражданнарны хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турындагы законнарны бозу очракларын ачулары өчен матди хуплау.

Хайваннар дөньясы объектларын саклауны, торгызауны һәм аннан тотрыклы файдалануны икътисадый кызыксындыру гамәлләрен башкару тәртибе законнарда билгеләнә.

## 6 бүлек. Хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында законнарны бозган өчен җаваплылык

**35 статья.** Хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында законнарны бозган өчен юридик җаваплылык

Хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турындагы законнарның таләпләрен бозуда гаепле юридик затлар һәм гражданнар законнар нигезендә юридик җаваплы булалар.

**36 статья.** Хайваннар дөньясы объектларына һәм аларның яшәү тирәлегенә зыян китергән өчен юридик затларның һәм гражданнарның җаваплылыгы

Хайваннар дөньясы объектларына һәм аларның яшәү тирәлегенә зыян китергән юридик затлар һәм гражданнар аны законнар нигезендә түләргә тиешләр.

**37 статья.** Хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану мәсьәләләре буенча бәхәсләрне хәл итү

Хайваннар дөньясын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану, хайваннар дөньясын файдалануга тапшыру мәсьәләләре буенча бәхәсләр законнарда билгеләнгән тәртиптә суд яисә арбитраж суды тарафыннан хәл ителә.

**38 статья.** Хайваннар дөньясының законсыз кулга төшерелгән объектларын һәм кулга төшерү коралларын тартып алу

Хайваннар дөньясының законсыз кулга төшерелгән объектлары, аларның аерым кисәкләре һәм алардан әзерләнгән продукция, шулай ук хайваннар дөньясы объектларын законсыз кулга төшерү кораллары, шул исәптән транспорт чаралары законнарда билгеләнгән тәртиптә алына.

215



Әлеге Законны бозып, табигый тирәлектән зерып алынган хайваннар дөньясы объектлары хокук бозучыдан законнар нигезендә тартып алына һәм яшәү тирәлегенә кире кайтарыла.

## 7 бүлек. Халыкара шартнамәләр

### 39 статья. Халыкара шартнамәләр

Әгәр Татарстан Республикасының халыкара шартнамәсендә әлеге Законда каралганнардан бүтән кагыйдәләр билгеләнсә, ул чакта халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1997 елның 2 июле
N1241